ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменения в Закон Республики Татарстан «О наделении органов местного самоуправления муниципальных образований в Республике Татарстан отдельными государственными полномочиями в сфере обеспечения равной доступности услуг общественного транспорта на территории Республики Татарстан для отдельных категорий граждан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
18 октября 2018 года

**Статья 1**

Внести в приложение к Закону Республики Татарстан от 19 декабря 2008 года № 123-ЗРТ «О наделении органов местного самоуправления муниципальных образований в Республике Татарстан отдельными государственными полномочиями в сфере обеспечения равной доступности услуг общественного транспорта на территории Республики Татарстан для отдельных категорий граждан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2008, № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть); 2012, № 11 (I часть); 2013, № 10) изменение, изложив его в следующей редакции:

«Приложение
к Закону Республики Татарстан
«О наделении органов местного
самоуправления муниципальных
образований в Республике Татарстан
отдельными государственными
полномочиями в сфере обеспечения
равной доступности услуг
общественного транспорта
на территории Республики Татарстан
для отдельных категорий граждан»

**МЕТОДИКА**
**расчета объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных образований из бюджета Республики Татарстан на осуществление отдельных государственных полномочий в сфере обеспечения равной доступности услуг общественного транспорта на территории Республики Татарстан для отдельных категорий граждан**

1. Настоящая Методика предназначена для расчета общего объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов (далее – муниципальное образование) из бюджета Республики Татарстан на осуществление органами местного самоуправления отдельных государственных полномочий в сфере обеспечения равной доступности услуг общественного транспорта на территории Республики Татарстан для отдельных категорий граждан.

2. Планируемый объем субвенций, предоставляемых бюджету i-го муниципального образования из бюджета Республики Татарстан на осуществление органами местного самоуправления государственных полномочий, определяется исходя из предельного максимального тарифа для оплаты проезда билетами длительного пользования на 50 и более поездок по j-му виду транспорта в городском сообщении и предельного максимального тарифа на регулярные перевозки пассажиров и багажа автомобильным транспортом в пригородном сообщении на один пассажирокилометр, установленных Государственным комитетом Республики Татарстан по тарифам, среднемесячного количества поездок в месяц по единому месячному социальному проездному билету и единому месячному детскому социальному проездному билету (электронной карте с льготным транспортным приложением), среднего количества реализованных единых месячных социальных проездных билетов и единых месячных детских социальных проездных билетов (среднего количества транзакций в городском и пригородном сообщении) в расчете на один месяц и установленной стоимости единого месячного социального проездного билета и единого месячного детского социального проездного билета (стоимости пополнения электронных карт с льготным транспортным приложением).

Объем субвенции, предоставляемой бюджету i-го муниципального образования, рассчитывается по формуле:

$C_i$ = (SUM ($T_{гор.}$ x $П_i$) x 12 месяцев) + ($T_{пр}$ x $P_{i\text{-}пр}$) x 12 месяцев) – $B_{орг}$,

где:

$C_i$ – размер субвенции, выделяемой i-му муниципальному образованию;

$T_{гор}$ – предельный максимальный тариф для оплаты проезда билетами длительного пользования на 50 и более поездок по j-му виду транспорта, установленный Государственным комитетом Республики Татарстан по тарифам;

$П_i$ – среднемесячное количество поездок в месяц по единому месячному

социальному проездному билету или единому месячному детскому социальному проездному билету (электронной карте с льготным транспортным приложением) за последний завершенный календарный год;

$Т_{пр}$ – предельный максимальный тариф на регулярные перевозки пассажиров и багажа автомобильным транспортом в пригородном сообщении, установленный Государственным комитетом Республики Татарстан по тарифам, на один пассажирокилометр;

$Р_{i\text{-}пр}$ – среднемесячное количество выполненных пассажирокилометров по данным операторов автоматизированной системы оплаты проезда (далее – система) за последний завершенный календарный год;

$В_{орг}$ – выручка транспортных организаций от реализации единых месячных социальных проездных билетов и единых месячных детских социальных проездных билетов (пополнения электронных карт с льготным транспортным приложением) в муниципальном образовании.

3. Среднемесячное количество поездок по единому месячному социальному проездному билету или единому месячному детскому социальному проездному билету (электронной карте с льготным транспортным приложением) определяется:

при наличии в i-ом муниципальном образовании персонифицированного учета поездок – исходя из данных системы за последний завершенный календарный год;

при отсутствии в i-ом муниципальном образовании персонифицированного учета поездок по формуле:

$$П_i = (Р_в + Р_д) \times 50 \text{ поездок},$$

где:

$Р_в$ – среднемесячное количество реализованных единых месячных социальных проездных билетов в муниципальном образовании за последний завершенный календарный год;

$Р_д$ – среднемесячное количество реализованных единых месячных детских социальных проездных билетов в муниципальном образовании за последний завершенный календарный год.

4. Выручка транспортных организаций от реализации единых месячных социальных проездных билетов и единых месячных детских социальных проездных билетов (пополнения электронных карт с льготным транспортным приложением) в муниципальном образовании рассчитывается по формуле:

$$В_{орг} = (Ц_в \times Р_в + Ц_д \times Р_д) \times 12 \text{ месяцев},$$

где:

$Ц_в$ – стоимость единого месячного социального проездного билета в расчетном периоде, установленная Кабинетом Министров Республики Татарстан;

$Ц_д$ – стоимость единого месячного детского социального проездного билета в расчетном периоде, установленная Кабинетом Министров Республики Татарстан.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2019 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
07 ноября 2018 года
№ 86-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 18 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 10), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасында муниципаль
берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына
Татарстан Республикасы территориясендә
гражданнарның аерым категорияләре өчен
җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез
дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү
өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен
бирү турында» Татарстан Республикасы
Законына кушымта

**Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләп чыгару методикасы**

1. Әлеге Методика Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары (алга таба – муниципаль берәмлек) бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен исәпләп чыгару өчен каралган.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан i-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенцияләрнең планлаштырыла торган күләме юлда йөргән өчен j-төр шәһәр транспортында 50 тапкыр һәм аннан күбрәк юл йөрүләргә озак вакытка исәпләнелгән билетлар белән түләү өчен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән иң чик максималь тарифтан һәм шәһәр яны автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга бер пассажир/километрга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән иң чик максималь тарифтан, бер айда бердәй айлык социаль юл йөрү билеты һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билеты (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карта) буенча юлда йөрүләрнең айлык уртача саныннан, бердәй айлык социаль юл йөрү билетларының һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетларының (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карталарның) бер айга исәпләгәндә сатылган уртача саныннан һәм бердәй айлык социаль юл йөрү билетының һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетының билгеләнгән бәясеннән (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карталарны тулыландыру бәясеннән) чыгып билгеләнә.

I-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенция күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$C_i = (SUM\,(T_{гор.} x\, П_i)\ x\ 12\ ай) + (T_{пр}\ x\ P_{i\text{-}пр})\ x\ 12\ ай) – B_{орг},$$

монда:

$C_i$ – i-муниципаль берәмлегенә бүлеп бирелә торган субвенция күләме;

$T_{гор}$ – юлда йөргән өчен j-төр транспортта 50 тапкыр һәм аннан күбрәк юл йөрүләргә озак вакытка исәпләнелгән билетлар белән түләү өчен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән иң чик максималь тариф;

$П_i$ – бер айда бердәй айлык социаль юл йөрү билеты һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билеты (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карта) буенча юлда йөрүләрнең тәмамланган соңгы календарь елда исәпләнгән айлык уртача саны;

$Т_{пр}$ – шәһәр яны автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүгә һәм багаж ташуга бер пассажир/километрга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән иң чик максималь тариф;

$Р_{i\text{-}пр}$ – юлда йөргән өчен автоматлаштырылган түләү системасы (алга таба – система) операторлары белешмәләре буенча тәмамланган соңгы календарь елда йөрелгән пассажир/километрларның айлык уртача саны;

$В_{орг}$ – муниципаль берәмлектә бердәй айлык социаль юл йөрү билетларын һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетларын сатудан (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карталарны тулыландырудан) транспорт оешмаларының табышы.

3. Бердәй айлык социаль юл йөрү билеты яки балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билеты (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карта) буенча юлда йөрүләрнең айлык уртача саны түбәндәгечә исәпләнә:

i-муниципаль берәмлегендә юлда йөрүләрнең персональ исәбе алып барылганда – системаның тәмамланган соңгы календарь ел белешмәләреннән чыгып;

i-муниципаль берәмлегендә юлда йөрүләрнең персональ исәбе алып барылмаганда түбәндәге формула буенча:

$П_i = (Р_в + Р_д)$ x 50 юл йөрү,

монда:

$Р_в$ – муниципаль берәмлектә бердәй айлык социаль юл йөрү билетларының тәмамланган соңгы календарь елда сатылган айлык уртача саны;

$Р_д$ – муниципаль берәмлектә балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетларының тәмамланган соңгы календарь елда сатылган айлык уртача саны.

4. Муниципаль берәмлектә бердәй айлык социаль юл йөрү билетларын һәм балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетларын сатудан (өстәмә транспорт ташламасы булган электрон карталарны тулыландырудан) транспорт оешмаларының кереме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$В_{орг} = (Ц_в \times Р_в + Ц_д \times Р_д)$ x 12 ай,

монда:

$Ц_в$ – исәпләү чорында бердәй айлык социаль юл йөрү билетының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән бәясе;

$Ц_д$ – исәпләү чорында балалар өчен бердәй айлык социаль юл йөрү билетының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән бәясе.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты                Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 07 ноябрь
№ 86-ТРЗ

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН